# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Мәгариф турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Мәгариф турында" 1993 елның 19 октябрендәге 1982-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1997 елның 2 июлендәге 1247 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 8 – 9; 2002, № 2; 2004, № 4 – 5; 2006, № 6 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2011, 5 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда "дәүләт мәгариф стандартларының милли-төбәк компонентлары" сүзләрен "федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә" сүзләренә алмаштырырга;

2) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"7 статья. **Төбәк, милли һәм этномәдәни үзенчәлекләрне төп үрнәк белем бирү программаларында гамәлгә ашыруны тәэмин итү**

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы органы, федераль дәүләт мәгариф стандартлары һәм (яисә) федераль дәүләт таләпләре нигезендә, төбәк, милли һәм этномәдәни үзенчәлекләргә туры китереп, төп үрнәк белем бирү программаларын эшләүдә катнаша.";

3) 10 статьяда:
а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"1. Татарстан Республикасында түбәндәге белем бирү программалары гамәлгә ашырыла:

а) гомуми белем бирү (төп, өстәмә, шул исәптән сәнгать өлкәсендә һөнәргә кадәр өстәмә гомуми белем бирү программалары);

б) һөнәри (төп, өстәмә);

в) һөнәри әзерлек.";

б) 4 пунктның "б" пунктчасына ", шул исәптән сәнгать өлкәсендә урта һөнәри белем бирүнең интеграцияләнгән белем бирү программалары" сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 4.1 пункт өстәргә:

"4.1. Сәнгать өлкәсендә югары иҗади сәләтләргә ия гражданнарга сәнгати белем һәм эстетик тәрбия алу өчен шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасында әлеге гражданнарның төп гомуми белем, урта (тулы) гомуми белем һәм урта һөнәри белем алуын, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерүгә юнәлдерелгән белемгә ихтыяҗларын һәм таләпләрен канәгатьләндерүне, аларның индивидуаль уку-укыту планнары буенча белем алуга, уку-укыту барышының эчтәлеге һәм аны оештыру үзенчәлекләрен исәпкә алып, тизләтелгән уку курсына хокукны тәэмин итә торган сәнгать өлкәсендә урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә сәнгать өлкәсендә урта һөнәри белем бирүнең интеграцияләнгән белем бирү программалары гамәлгә ашырыла.";

г) 5 пунктка "тәрбияләнүчеләрнең белемгә ихтыяҗларын һәм таләпләрен" сүзләреннән соң ", төбәк, милли һәм этномәдәни үзенчәлекләрне" сүзләрен өстәргә;

д) 5.2 пунктка "федераль" сүзе алдыннан "мондый белем бирү программасын гамәлгә ашырганда мәҗбүри булган" сүзләрен өстәргә;

е) 5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.3. Югары һөнәри уку йортыннан соңгы (докторантурадан тыш) төп һөнәри белем бирү программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре билгеләнә.

Югары һөнәри уку йортыннан соңгы төп һөнәри белем бирү программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре аспирантурада (адъюнктурада) укучылар өчен – мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы, ассистентура-стажировка рәвешендә укучылар өчен – мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы, ординатурада, интернатурада укучылар өчен сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.";

ж) 6 пунктның өченче абзацына "федераль законнарда" сүзләреннән соң ", Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында яисә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында" сүзләрен өстәргә;

з) түбәндәге эчтәлекле 6.1 пункт өстәргә:

"6.1. Сәнгать өлкәсендә һөнәргә кадәр өстәмә гомуми белем бирү программаларының эчтәлеге минимумына, структурасына һәм аларны гамәлгә ашыру шартларына һәм әлеге программалар буенча уку-укыту срокларына, мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы белән килештереп, мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан федераль дәүләт таләпләре билгеләнә.";

и) түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

"8. Югары һөнәри уку йортыннан соңгы (докторантурадан тыш) төп һөнәри белем бирү программасы структурасына, өстәмә һөнәри белем бирү программасы эчтәлегенең минимумына һәм һөнәри яңадан әзерләү дәрәҗәсенә федераль дәүләт таләпләре тиешле белем бирү программаларын дәүләт аккредитациясе булган мәгариф учреждениеләре һәм фәнни оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырганда мәҗбүри булалар.";

4) 13 статьяда:

а) 5 һәм 6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Мәгариф учреждениесе юридик зат була, Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелә һәм теркәлә.

6. Бер типтагы мәгариф учреждениеләре дәүләт һәм муниципаль мәгариф учреждениеләре эшчәнлеген җайга сала торган федераль законнарда яисә тиешле типтагы һәм төрдәге мәгариф учреждениеләре турында типик нигезләмәләрдә билгеләнгән төрләргә бүленәләр. Мондый типик нигезләмәләр нигезендә әлеге мәгариф учреждениеләренең уставлары эшләнә.

Дәүләткә карамаган мәгариф учреждениеләре өчен типик нигезләмәләр үрнәк функцияләрен башкаралар.";

б) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9. Мәгариф учреждениесенең тибы һәм төре мәгариф учреждениесен төзегәндә гамәлгә куючы (гамәлгә куючылар) тарафыннан билгеләнә һәм гамәлгә куючы (гамәлгә куючылар) карары буенча үзгәртелә.

Мәгариф учреждениесенә дәүләт аккредитациясе үткәргәндә, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, аның мәгариф учреждениесе тибын һәм (яисә) төрен раслый яисә үзгәртә торган дәүләт статусы билгеләнә.";

5) 15 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5.2 пункт өстәргә:

"5.2. Төп үрнәк белем бирү программаларында төбәк, милли һәм этномәдәни үзенчәлекләр исәпкә алынырга тиеш.";

6) 16 статьяда:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирү программаларын һәм һөнәри белем бирү программаларын үзләштерү укучыларның мәҗбүри йомгаклау аттестациясе белән тәгәлләнә. Дәүләт аккредитациясе булган мәгариф учреждениеләрендә шушы белем бирү программаларын үзләштерү укучыларның мәҗбүри дәүләт (йомгаклау) аттестациясе белән тәгәлләнә.

Урта (тулы) гомуми белем бирү программаларын үзләштергән укучыларга дәүләт (йомгаклау) аттестациясе, әгәр "Мәгариф турында" 1992 елның 10 июлендәге 3266-1 номерлы Россия Федерациясе Законында башкасы билгеләнмәгән булса, бердәй дәүләт имтиханы рәвешендә үткәрелә. Урта (тулы) гомуми белем бирү программаларын үзләштергән укучыларга дәүләт (йомгаклау) аттестациясен үткәрүнең башка рәвешләре түбәндәгеләр тарафыннан билгеләнергә мөмкин:

мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан – девиант (җәмгыять өчен куркыныч) холыклы балалар һәм яшүсмерләр өчен ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләрендә, шулай ук ирекләрдән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдә урта (тулы) гомуми белем бирү программаларын үзләштергән укучылар өчен яисә урта (тулы) гомуми белем бирү программаларын үзләштергән сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган укучылар өчен;

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы органы тарафыннан – төп гомуми белем һәм урта (тулы) гомуми белем алганда туган телен һәм әдәбиятын (туган телендә милли әдәбиятны) өйрәнгән һәм дәүләт (йомгаклау) аттестациясен үтү өчен туган теле һәм әдәбияты буенча имтихан сайлаган затлар өчен.

Сәнгать өлкәсендә урта һөнәри белем бирүнең интеграцияләнгән белем бирү программаларын үзләштергән укучылар төп гомуми белем бирү һәм урта (тулы) гомуми белем бирү программаларын үзләштерүне тәгәлли торган дәүләт (йомгаклау) аттестациясе һәм урта һөнәри белем бирүнең тиешле белем бирү программасын үзләштерүне тәгәлли торган дәүләт (йомгаклау) аттестациясе үтәләр.";

б) түбәндәге эчтәлекле 4.1 пункт өстәргә:

"4.1. Төп гомуми белем яисә урта (тулы) гомуми белем бирү программаларын үзләштергән укучыларга дәүләт (йомгаклау) аттестациясен үткәрү тәртибен үтәүне тәэмин итү максатларында аны үткәргәндә гражданнарга иҗтимагый күзәтүчеләр буларак катнашу һәм алар тарафыннан табылган хокук бозулар турындагы мәгълүматны мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органына, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы органына яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына гамәлгә ашыру өчен мәгариф өлкәсендә тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына җибәрү хокукы бирелә.

Иҗтимагый күзәтүчеләр буларак гражданнарны аккредитацияләү аларның гаризалары буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы органы яисә мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.";

в) 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.1. Бердәй дәүләт имтиханын үткәрүне һәм гражданнарны урта һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләренә һәм югары һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләренә кабул итүне мәгълүмати тәэмин итү максатларында, бердәй дәүләт имтиханын үткәрүне тәэмин итүнең төбәк мәгълүмат системасы (алга таба – төбәк мәгълүмат системасы) төзелә. Күрсәтелгән мәгълүмат системасын булдыруны һәм алып баруны оештыру Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы органы тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы органы, урта һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләре һәм югары һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләре федераль мәгълүмат системасына бердәй дәүләт имтиханын үткәрүне һәм гражданнарны урта һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләренә һәм югары һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләренә кабул итүне мәгълүмати тәэмин итү өчен кирәкле белешмәләрне кертәләр. Урта (тулы) гомуми белемнең, башлангыч һөнәри белемнең, урта һөнәри белемнең, югары һөнәри белемнең төп белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре, җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы органы төбәк мәгълүмат системасына бердәй дәүләт имтиханын үткәрүне мәгълүмати тәэмин итү өчен кирәкле белешмәләрне кертәләр.

Төбәк мәгълүмат системасын булдыру һәм алып бару тәртибе (андагы белешмәләр исемлеген, аларны мәгълүмат системасына кертү тәртибен, әлеге белешмәләрне саклау, эшкәртү һәм файдалану һәм алардан файдалана алуны тәэмин итү тәртибен, әлеге белешмәләрне саклау срогы һәм аларны яклауны тәэмин итү тәртибен, мәгълүмат системаларының үзара эшчәнлеген тәэмин итү тәртибен кертеп) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.";

г) түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

"8. Бердәй дәүләт имтиханын, укучыларның дәүләт (йомгаклау) аттестациясен, мәктәп укучылары олимпиадаларын, урта һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләре һәм югары һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләре уздыра торган керү сынауларын үткәрү урыннарында әлеге чараларны үткәрү вакытында элемтә чараларын һәм электрон-исәпләү техникасын (шул исәптән калькуляторларны) урнаштыру, күрсәтелгән чараларда катнашучыларга һәм аларны үткәрүгә җәлеп ителә торган затларга аларны үзләрендә булдыру һәм файдалану, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән очраклардан тыш, тыела.";

7) 20 статьяның 1 пунктындагы өченче абзацында "яисә Мәгариф буенча белгечлекләрнең гомумроссия классификаторында" сүзләрен ", Мәгариф буенча белгечлекләрнең гомумроссия классификаторында яисә Югары фәнни квалификация белгечлекләренең гомумроссия классификаторында" сүзләренә алмаштырырга;

8) 22 статьяда:

а) 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Сәнгать өлкәсендә урта һөнәри белем бирүнең интеграцияләнгән белем бирү программалары буенча сәнгать өлкәсендә урта звено белгечләрен әзерләү башлангыч гомуми белем бирү базасында гамәлгә ашырыла башлый.";

б) 4 пунктта "биремнәре (контроль саннары)" сүзләрен "контроль саннар нигезендә эшләнә торган дәүләт биремнәре" сүзләренә алмаштырырга;

9) 23 статьяның 4 пунктындагы 2 пунктчасына "белгеч" сүзе алдыннан "әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса," сүзләрен өстәргә;

10) 24 статьяның 2 пунктына "докторантурада" сүзеннән соң "һәм күрсәтелгән мәгариф учреждениеләрендә ассистентура-стажировка рәвешендә укыганда" сүзләрен өстәргә;

11) 25 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

"1.1. Сәнгать өлкәсендә һөнәргә кадәр өстәмә гомуми белем бирү программалары сәләтле балаларны сабый чактан ук ачыклау, аларга сәнгать белеме һәм эстетик тәрбия бирү, сәнгатьнең сайланган төре өлкәсендә белемнәр, осталык һәм күнекмәләр, иҗади эшчәнлек тәҗрибәсе алу һәм аларны сәнгать өлкәсендә һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә кертүгә әзерләү өчен шартлар тудыру максатларында гамәлгә ашырыла.

Күрсәтелгән белем бирү программаларын үзләштерү укучыларның йомгаклау аттестациясе белән төгәлләнә, аны үткәрү рәвешләре һәм тәртибе мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы белән килештереп билгеләнә.

Сәнгать өлкәсендә һөнәргә кадәр өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүне төгәлли торган йомгаклау аттестациясен узган затларга әлеге программаларны үзләштерү турында тиешле мәгариф учреждениесе мөһере белән таныкланган, мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән рәвештәге таныклык бирелә.";

б) 2 пунктның өченче абзацында "музыка һәм художество мәктәпләрендә, сәнгать мәктәпләрендә" сүзләрен "балалар сәнгать мәктәпләрендә (шул исәптән сәнгатьнең төрле төрләре буенча)" сүзләренә алмаштырырга;

12) 27 статьяда:

а) 1 – 3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Мәгариф учреждениесе яисә фәнни оешма йомгаклау аттестациясен үткән затларга лицензия нигезендә тиешле белем һәм (яисә) квалификация турында документлар бирә. Күрсәтелгән документларның рәвеше мәгариф учреждениесенең яисә фәнни оешманың үзе тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән документлар мәгариф учреждениесе яисә фәнни оешма мөһере белән таныклана.

2. Дәүләт (йомгаклау) аттестациясен үткән затларга дәүләт аккредитациясе булган мәгариф учреждениесе яисә фәнни оешма үзләре гамәлгә ашыра торган аккредитацияләнгән белем бирү программалары буенча белем һәм (яисә) квалификация дәрәҗәсе турында дәүләт үрнәгендәге документлар бирәләр.

Мәгариф учреждениеләре һәм фәнни оешмалар, дини һөнәри белем бирү учреждениеләреннән (рухи белем бирү учреждениеләреннән) тыш, белем һәм (яисә)

квалификация дәрәҗәсе турында үзләре бирә торган дәүләт үрнәгендәге документларны Россия Федерациясе Дәүләт гербы сурәте төшерелгән мөһер белән таныклыйлар.

Дини һөнәри белем бирү учреждениесе (рухи белем бирү учреждениесе) мондый документларны Россия Федерациясе Дәүләт гербы сурәте төшерелмәгән үз мөһере белән таныклый.

3. Тиешле белем дәрәҗәсе турында дәүләт үрнәгендәге документ дәүләт яисә муниципаль мәгариф учреждениесендә йә фәнни оешмада белем дәрәҗәсен күтәрү программалары буенча белем алуны дәвам итү өчен кирәкле шарт булып тора.

Башлангыч һөнәри, урта һөнәри, югары һөнәри, югары һөнәри уку йортыннан соңгы һөнәри белем турындагы документларда күрсәтелгән квалификацияләр һәм гыйльми дәрәҗәләр турындагы документларда күрсәтелгән фәнни дәрәҗәләр аларга ия булучыларга һөнәри эшчәнлек белән шөгыльләнү, шул исәптән тиешле мәгариф цензына карата билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри квалификация таләпләре куелган вазыйфаларны биләү хокукын бирәләр.";

б) 5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Төп гомуми, урта (тулы) гомуми белемнең төп гомуми белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләре буенча дәүләт (йомгаклау) аттестациясен үтмәгән яисә күрсәтелгән аттестациядә нәтиҗәләре канәгатьләнерлек булмаган затлар дәүләт (йомгаклау) аттестациясен бер елдан соң гына кабат үтәргә хокуклы. Һөнәри белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләре буенча дәүләт (йомгаклау) аттестациясен үтмәгән яисә күрсәтелгән аттестациядә нәтиҗәләре канәгатьләнерлек булмаган затлар дәүләт (йомгаклау) аттестациясен тиешле белем бирү программалары буенча укучыларга дәүләт (йомгаклау) аттестациясен үткәрү тәртибендә билгеләнгән срокларда кабат үтәргә хокуклы.";

13) II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 27.1 статья өстәргә:

"27.1 статья. **Белем турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында дәүләт үрнәгендәге документларны раслау**

1. Белем турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында дәүләт үрнәгендәге документларны аларда апостиль кую юлы белән раслау Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең белем турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында дәүләт үрнәгендәге документларны раслау буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан башкарыла.

2. Белем турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында дәүләт үрнәгендәге документларны раслау гражданнарның язма рәвештә бирелгән яисә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан файдаланып, электрон документлар рәвешендә бирелгән гаризалары буенча Россия Федерациясе халыкара шартнамәләре һәм (яисә) Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Белем турында, гыйльми дәрәҗә яисә гыйльми исем турында дәүләт үрнәгендәге документта апостиль куйган өчен салымнар һәм җыемнар хакында

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм күләмнәрдә мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт пошлинасы түләнә.

Белем турында, гыйльми дәрәҗә яисә гыйльми исем турында дәүләт үрнәгендәге документны раслау хакында, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә гариза биргәндә, белем турында, гыйльми дәрәҗә яисә гыйльми исем турында дәүләт үрнәгендәге документта апостиль куйган өчен дәүләт пошлинасын түләү хакындагы документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең белем турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында дәүләт үрнәгендәге документларны раслау буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органы белем турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында дәүләт үрнәгендәге документларда куелган апостильләр хакындагы белешмәләрне Россия Федерациясе законнары нигезендә аларны федераль күрсәткечләр базасына кертү юлы белән мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органына тапшыра. Мондый орган белем турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында дәүләт үрнәгендәге документларда куелган апостильләр хакында федераль күрсәткечләр базасындагы белешмәләрдән файдаланырга хокуклы.";

14) 29 статьяның 2 һәм 3 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасында мәгарифне үстерүнең комплекслы республика максатчан программасын, шулай ук, милли һәм төбәк социаль-икътисадый, экологик, мәдәни, демографик һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, мәгарифне үстерүнең башка программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2) федераль дәүләт мәгариф стандартлары яисә федераль дәүләт таләпләре нигезендә төп үрнәк белем бирү программаларын аларның дәрәҗәсен һәм юнәлешен исәпкә алып (төбәк, милли һәм этномәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алу өлешендә) эшләүдә катнашу;

3) төп гомуми белем яисә урта (тулы) гомуми белем бирү программаларын үзләштергән укучыларга дәүләт (йомгаклау) аттестациясен, шул исәптән бердәй дәүләт имтиханы рәвешендәге аттестацияне тәэмин итү һәм үткәрү (бердәй дәүләт имтиханын үткәрүгә җәлеп ителә торган затларны әзерләүне, төбәк мәгълүмат системасын булдыруны һәм алып баруны оештыруны, имтихан материалларын һәм бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре турындагы таныклыкларны саклауны, куллануны һәм юкка чыгаруны тәэмин итүне, бердәй дәүләт имтиханында катнашучыларның имтихан бирү эшләрен эшкәртүне һәм тикшерүне, шулай ук бердәй дәүләт имтиханында катнашучыларны аның нәтиҗәләре белән

таныштыруны тәэмин итүне һәм иҗтимагый күзәтүчеләрне аккредитацияләүне кертеп);

4) төп гомуми белем һәм урта (тулы) гомуми белем алганда туган телен һәм әдәбиятын өйрәнгән затларга туган тел һәм әдәбият буенча дәүләт (йомгаклау) аттестациясен үткәрү рәвешләрен һәм тәртибен билгеләү;

5) Татарстан Республикасы мәгариф учреждениеләрен төзү, үзгәртеп кору, бетерү һәм финанс белән тәэмин итү тәртибен законнар нигезендә билгеләү;

6) югары һөнәри белем бирү өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасындагы килешүләрне гамәлгә ашыру;

7) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә махсус вәкаләтле органы турындагы нигезләмәне раслау;

8) гражданнарның гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алу хокукларына дәүләт гарантияләрен гомуми белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын, дәреслекләргә һәм уку-укыту ярдәмлекләренә, техник укыту чараларына, күндәлек материалларга һәм хуҗалык ихтыяҗларына чыгымнарны (биналарны тоткан һәм коммуналь чыгымнар өчен җирле бюджетлардан гамәлгә ашырыла торган чыгымнардан тыш) Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә торган нормативлар нигезендә финанслау өлешендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә җирле бюджетларга субвенцияләр бүлеп бирү юлы белән тәэмин итү;

9) сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә, ачык һәм ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләрендә, озак дәвалауга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыру мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирүне (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган федераль мәгариф учреждениеләрендә алына торган белемнән тыш) Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә торган нормативлар нигезендә оештыру;

10) республика әһәмиятендәге учреждениеләрдә балаларга өстәмә белем бирүне оештыру;

11) башлангыч, урта һәм өстәмә һөнәри белем бирүне (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган федераль мәгариф учреждениеләрендә алына торган белемнән тыш) оештыру;

12) Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф учреждениеләрен төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү (югары уку йортларын төзүдән тыш);

13) Татарстан Республикасы бюджетын мәгарифкә чыгымнар өлешендә төзү;

14) Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф учреждениеләре өчен төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, санитар нормалар, укучыларның,

тәрбияләнүчеләрнең сәламәтлеген саклау, уку-укыту процессын һәм уку биналарын җиһазлау өлешендә мәгариф учреждениеләренә куелган федераль таләпләргә өстәмәләр билгеләү;

15) үз компетенциясе чикләрендә мәгариф учреждениеләрен мәгълүмат белән тәэмин итү, дәүләт аккредитациясе булган һәм гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә белем бирү барышында кулланырга тәкъдим ителгән яисә рөхсәт ителгән дәреслекләрнең федераль исемлекләре нигезендә дәреслекләр белән һәм шундый мәгариф учреждениеләрендә белем бирү барышында кулланырга рөхсәт ителгән уку-укыту ярдәмлекләре белән тәэмин итүне оештыру;

16) дәүләт аккредитациясе булган һәм гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә белем бирү барышында кулланырга рөхсәт ителә торган уку-укыту ярдәмлекләрен чыгаруны туган тел һәм әдәбият буенча уку-укыту ярдәмлекләрен бастырып чыгару өлешендә гамәлгә ашыручы оешмаларны сайлап алуда катнашу;

17) Татарстан Республикасы мәгариф учреждениеләренең һәм муниципаль мәгариф учреждениеләренең педагогика хезмәткәрләрен әзерләүне, яңадан әзерләүне, аларның квалификациясен күтәрүне һәм аларга аттестация уздыруны оештыру;

18) үз компетенциясе чикләрендә норматив документлар бастырып чыгару;

19) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары муниципаль мәгариф учреждениеләрендә һәм дәүләт аккредитациясе булган дәүләткә карамаган гомуми белем бирү оешмаларында тукландыруны оештыру гамәлләрен өстәмә финанслау, шулай ук балалар өчен муниципаль сәнгать мәктәпләрендә сәнгать өлкәсендә һөнәргә кадәр өстәмә гомуми белем бирү программаларын реализацияләүдә дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру хокукына ия булалар.";

15) 29.1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"29.1 статья. **Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына гамәлгә ашыру өчен мәгариф өлкәсендә тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары "Мәгариф турында" 1992 елның 10 июлендәге 3266-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына гамәлгә ашыру өчен мәгариф өлкәсендә тапшырылган Россия Федерациясенең түбәндәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыра:

1) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф учреждениеләренә ("Мәгариф турында" 1992 елның 10 июлендәге 3266-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 28 статьясындагы 24 пунктчасында күрсәтелгән мәгариф учреждениеләреннән тыш), мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларга, шулай ук мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарына карата мәгариф өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген);

2) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф учреждениеләренең ("Мәгариф турында" 1992 елның 10 июлендәге 3266-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 28 статьясындагы 24 пунктчасында күрсәтелгән мәгариф учреждениеләреннән тыш) мәгариф эшчәнлеген лицензияләү һәм аларны дәүләт тарафыннан аккредитацияләү, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм структур бүлекчәләре һөнәри әзерлек программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларның мәгариф эшчәнлеген лицензияләү, шулай ук аккредитацияләнгән мәгариф учреждениеләренең эшчәнлеге турында белешмәләре булган дәүләт аккредитациясенең төбәк мәгълүмат системасын булдыру, алып бару һәм алардан файдалануны тәэмин итү;

3) белем турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында дәүләт үрнәгендәге документларны раслау.

2. Әлеге статьяның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бәйле һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган тиешле дәүләт пошлинасын түләүдән Татарстан Республикасы бюджетына планлаштырыла торган кертемнәрдән ким булмаган күләмдә Татарстан Республикасы бюджетында шушы максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге статьяның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү, белем турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында дәүләт үрнәгендәге документларны раслау вәкаләтләреннән тыш, шулай ук федераль бюджеттан субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.";

16) 32 статьяда:

а) 2 пунктта:

"б" пунктчасына ", шулай ук мәгариф учреждениесе эшчәнлеген үзбәяләү нәтиҗәләре турында хисап тоту (үз-үзен тикшерү)" сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле "ц" – "ш" пунктчалары өстәргә:

"ц) мәгариф учреждениесендә белем бирү сыйфатын эчке мониторинглау системасының эшләвен тәэмин итү;

ч) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгариф учреждениесенең рәсми сайтын булдыруны һәм алып баруны тәэмин итү;

ш) белем бирү процессының һәм белем бирү технологияләренең, шул исәптән дистанцион белем бирү технологияләренең, методикаларын куллану һәм камилләштерү. Дистанцион белем бирү технологияләре дигәндә укучы белән педагогика хезмәткәре арасында читтән торып (ерактан торып) яисә өлешчә читтән торып хезмәттәшлек иткәндә башлыча мәгълүмат һәм телекоммуникация технологияләрен кулланып гамәлгә ашырыла торган белем бирү технологияләре аңлашыла.

Мәгариф учреждениесе мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә белем алуның барлык рәвешләрендә дистанцион белем бирү технологияләрен кулланырга хокуклы.";

б) түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 пунктлар өстәргә:

"4. Мәгариф учреждениесе түбәндәге мәгълүматның ачык һәм һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итә:

1) белешмәләрнең:

мәгариф учреждениесенең оешу датасы турындагы;

мәгариф учреждениесе структурасы турындагы;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты чаралары исәбеннән укучы затлар санын күрсәтеп, укыту хакын физик һәм (яисә) юридик затлар тарафыннан түләгән килеш, алар белән шартнамәләр буенча гамәлгә ашырыла торган төп һәм өстәмә белем бирү программалары турындагы;

белем бирү стандартлары турындагы һәм "Мәгариф турында" 1992 елның 10 июлендәге 3266-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 7 статьясындагы 2 пункты нигезендә югары һөнәри белемнең федераль дәүләт мәгариф учреждениеләре тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнгән таләпләр хакындагы (алар булган очракта);

белем дәрәҗәсен һәм квалификациясен күрсәтеп, педагогика хезмәткәрләренең персональ составы турындагы;

белем бирү барышының матди-техник тәэмин ителеше турындагы һәм җиһазландырылуы хакындагы (шул исәптән китапханә, тулай тораклар, спорт корылмалары булу турындагы, тукландыру, медицина хезмәте күрсәтү шартлары турындагы, мәгълүмат системаларының һәм мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләренең һәркем өчен мөмкин булуы турындагы);

укучыларның файдалана алуын тәэмин итә торган электрон белем бирү ресурслары турындагы;

фәнни-тикшеренү эшчәнлеге юнәлешләре һәм аны гамәлгә ашыру базасы турындагы (югары һөнәри белемнең мәгариф учреждениеләре өчен);

урта һөнәри белемгә яисә югары һөнәри белемгә әзерлекнең (белгечлекнең) һәр юнәлеше буенча, барлык керү сынаулары буенча җыелган балларның уртача суммасын күрсәтеп, кабул итүнең төрле шартлары буенча кабул итү (Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты чаралары исәбеннән финанслана торган, физик һәм (яисә) юридик затлар тарафыннан укыту хакын түләгән килеш, алар белән шартнамәләр буенча укуга кабул итү) нәтиҗәләре турындагы (бары тик урта һөнәри белемнең һәм (яисә) югары һөнәри белемнең төп һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре өчен);

стипендияләрнең һәм бүтән матди ярдәм төрләренең булуы турындагы, аларны укучыларга бирү шартлары хакындагы;

финанс елы йомгаклары буенча финанс һәм матди чараларның керүе һәм аларны тоту турындагы;

2) күчермәләренең:

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиянең булуын раслый торган документның (кушымталары белән);

дәүләт аккредитациясе турындагы таныклыкның (кушымталары белән);

мәгариф учреждениесенең билгеләнгән тәртиптә расланган финанс-хуҗалык эшчәнлеге планының яисә бюджет сметасының;

3) үз-үзен тикшерү нәтиҗәләре турындагы хисапның;

4) түләүле мәгариф хезмәтләренең хакын күрсәтеп, түләүле мәгариф хезмәтләре күрсәтү тәртибенең, шул исәптән түләүле мәгариф хезмәтләрен күрсәтү турында шартнамә үрнәгенең;

5) "Коммерциячел булмаган оешмалар турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясындагы 3.2 пунктында күрсәтелгән белешмәләрнең.

5. Әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгариф учреждениесенең рәсми сайтында урнаштырылырга һәм тиешле үзгәрешләр кертелгән көннән алып 30 көн эчендә яңартылырга тиеш.

Мәгариф учреждениесе турындагы мәгълүматны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм яңарту тәртибе, шул исәптән аның эчтәлеге һәм бирү рәвеше, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.";

17) 35 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"35 статья. **Мәгариф учреждениесен үзгәртеп кору һәм бетерү**

1. Мәгариф учреждениесе федераль законнар нигезендә бүтән коммерциячел булмаган мәгариф оешмасына үзгәртеп корылырга мөмкин. Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф учреждениеләрен үзгәртеп кору тәртибе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, муниципаль мәгариф учреждениеләрен үзгәртеп кору тәртибе муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе тарафыннан билгеләнә.

2. Мәгариф учреждениесен бетерү түбәндәгечә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә – Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт мәгариф учреждениеләре өчен, муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә – муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен;

тиешле лицензиясез (рөхсәтсез) эшчәнлекне, йә закон белән тыелган эшчәнлекне, йә аның устав максатларына туры килми торган эшчәнлекне башкарган очракта – суд карары буенча.

3. Авылның мәктәпкәчә мәгариф учреждениесен яисә гомуми белем бирү учреждениесен бетерү әлеге учреждение хезмәт күрсәтә торган торак пунктлар халкының җыены ризалыгы белән генә рөхсәт ителә.";

18) 35.1 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"35.1 статья. **Мәгариф өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге)**";

б) 1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Мәгариф өлкәсендә дәүләт контроленә (күзәтчелегенә) мәгариф өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеге һәм белем бирү сыйфатына федераль дәүләт контроле керә.

Мәгариф өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеге һәм белем бирү сыйфатына федераль дәүләт контроле вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары һәм мәгариф өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Мәгариф өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеге дигәндә Россия Федерациясе законнары белән мәгариф өлкәсендә билгеләнгән таләпләрне мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук мәгариф эшчәнлеге белән шөгыльләнүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре һәм бүтән вазыйфаи затлар (алга таба әлеге статья максатлары өчен – юридик затлар) тарафыннан бозуларны, шушы затларны тикшерүләрне оештыру һәм уздыру, ачыкланган бозуларның нәтиҗәләрен булдырмый калу һәм (яисә) бетерү буенча Россия Федерациясе законнары белән каралган чаралар күрү юлы белән, кисәтүгә, ачыклауга һәм булдырмый калуга юнәлдерелгән вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының һәм Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимияте органы эшчәнлеге һәм дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм юридик затларның үз эшчәнлеген башкарганда мәгариф өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәүләрен даими рәвештә күзәтү, аларның мәгариф өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәүләре торышын анализлау һәм фаразлау буенча дәүләт хакимиятенең әлеге вәкаләтле органнары эшчәнлеге аңлашыла.

Мәгариф өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын мәгариф учреждениесе, фәнни оешма, мәгариф эшчәнлеген башкаручы бүтән оешма, мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы тарафыннан бозу ачыкланган очракта, мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы мондый мәгариф учреждениесенә, фәнни оешмага, бүтән оешмага һәм (яисә) гамәлгә куючыга, мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына, мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органына ачыкланган бозуны бетерү турында күрсәтмә бирә.

Әлеге күрсәтмәдә аны үтәү срогы билгеләнә, ул алты айдан да арта алмый.

Мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы белән билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозу турында эш кузгата. Мәгариф учреждениесе, фәнни оешма яисә мәгариф эшчәнлеген башкаручы бүтән оешма, гамәлгә куючы, мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органына әлеге күрсәтмәне үтәве турында хисап тапшыра, аңа күрсәтмәне үтәүне раслый торган белешмәләре булган документлар керә.

Әлеге күрсәтмәне мондый мәгариф учреждениесе, фәнни оешма, бүтән оешма, гамәлгә куючы, мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә

ашыручы җирле үзидарә органы үтәмәгән очракта (шул исәптән әлеге күрсәтмәне үтәү турындагы хисап мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органына әлеге күрсәтмәдә билгеләнгән срок тәмамланганчы тапшырылмаган булса яисә тапшырылган хисап әлеге күрсәтмәнең билгеләнгән срокта үтәлүен расламаса), мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы белән билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозу турында эш кузгата. Әлеге күрсәтмәне мондый мәгариф учреждениесе, фәнни оешма яисә бүтән оешма һәм (яисә) гамәлгә куючы үтәмәгән очракта, мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы шулай ук мондый мәгариф учреждениесенең, фәнни оешманың яисә бүтән оешманың лицензиясенең гамәлдә булуын тулысынча яисә аерым белем бирү программаларына карата, мондый мәгариф учреждениесенең, фәнни оешманың яисә бүтән оешманың филиалларының мәгариф эшчәнлегенә, мәгариф эшчәнлеген башкару урынына карата алты айдан да артмаган срокка туктатып тора.

Мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору турында карар кабул иткән көннән соң өч көн эчендә лицензияләр реестрына тиешле язма кертә. Мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы әлеге карарны кабул иткән көннән биш эш көне эчендә тиешле карар кабул итүне раслый торган документның күчермәсен, юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына шул турыдагы хат белән бергә, лицензиат урнашкан урын буенча җибәрә.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору срогы тәмамланганчы лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору өчен нигез булган үтәлмәгән күрсәтмәне үтәүне раслый торган белешмәләре булган документлар мондый мәгариф учреждениесе, фәнни оешма яисә бүтән оешма һәм (яисә) гамәлгә куючы тарафыннан мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органына тапшырылса, мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы лицензиянең гамәлдә булуын торгыза.

Әлеге документлар лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору срогы тәмамланганчы мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органына мондый мәгариф учреждениесе, фәнни оешма яисә бүтән оешма һәм (яисә) гамәлгә куючы тарафыннан тапшырылмаган йә тапшырылган документлар әлеге күрсәтмәне үтәүне расламаган очракта, мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы лицензияне юкка чыгару турындагы гариза белән судка мөрәҗәгать итә. Лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору суд карары закон көченә кергәнче озайтыла.

Лицензия лицензияләүче орган гаризасын карау нигезендә суд карары белән юкка чыгарыла.

2. Белем бирү сыйфатына федераль дәүләт контроле дигәндә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының һәм Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимияте органының мәгариф учреждениесендә яисә фәнни оешмада укучыларның һәм аны тәмамлаганнарның әзерлеге эчтәлегенең һәм (яисә) сыйфатының федераль дәүләт мәгариф стандартлары таләпләренә яисә федераль дәүләт таләпләренә туры килүен белем бирү сыйфатын тикшерүләр уздыру һәм федераль дәүләт мәгариф стандартлары таләпләрен яисә федераль дәүләт

таләпләрен ачыкланган бозуларны булдырмый калу һәм (яисә) бетерү буенча Россия Федерациясе законнары белән каралган чаралар күрү юлы белән бәяләүгә юнәлдерелгән эшчәнлеге аңлашыла.

Федераль дәүләт мәгариф стандарты таләпләрен яисә федераль дәүләт таләпләрен мәгариф учреждениесе яисә фәнни оешма тарафыннан бозу ачыкланган очракта, мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы мәгариф учреждениесенә яисә фәнни оешмага һәм (яисә) гамәлгә куючыга ачыкланган бозуны бетерү турында күрсәтмә бирә.

Әлеге күрсәтмәдә аны үтәү срогы билгеләнә, ул алты айдан да арта алмый.

Мәгариф учреждениесе яисә фәнни оешма һәм (яисә) гамәлгә куючы мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органына әлеге күрсәтмәне үтәве турында хисап тапшыра, аңа күрсәтмәне үтәүне раслый торган белешмәләре булган документлар кертә.

Әлеге күрсәтмәне мондый мәгариф учреждениесе, фәнни оешма, гамәлгә куючы үтәмәгән очракта (шул исәптән әлеге күрсәтмәне үтәү турындагы хисап мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органына әлеге күрсәтмәдә билгеләнгән срок тәмамланганчы тапшырылмаган булса яисә тапшырылган хисап әлеге күрсәтмәнең билгеләнгән срокта үтәлүен расламаса), мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы белән билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозу турында эш кузгата. Әлеге күрсәтмәне аккредитацияләнгән мәгариф учреждениесе яисә фәнни оешма һәм (яисә) гамәлгә куючы үтәмәгән очракта, мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы шулай ук дәүләт аккредитациясе турындагы таныклыкның гамәлдә булуын тулысынча яисә аерым белем бирү программаларына карата, мондый мәгариф учреждениесендә яисә фәнни оешмада һәм (яисә) аларның филиалларында гамәлгә ашырыла торган әзерлек һәм белгечлекләр юнәлешләренең эреләндерелгән төркемнәренә карата алты айдан да артмаган срокка туктатып тора.

Дәүләт аккредитациясе турындагы таныклыкның гамәлдә булуын туктатып тору срогы тәмамланганчы дәүләт аккредитациясе турындагы таныклыкның гамәлдә булуын туктатып тору өчен нигез булган үтәлмәгән күрсәтмәне үтәүне раслый торган белешмәләре булган документлар мәгариф учреждениесе яисә фәнни оешма һәм (яисә) гамәлгә куючы тарафыннан мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органына тапшырылса, мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы дәүләт аккредитациясе турындагы таныклыкның гамәлдә булуын торгыза.

Мондый документлар дәүләт аккредитациясе турындагы таныклыкның гамәлдә булуын туктатып тору срогы тәмамланганчы мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органына мәгариф учреждениесе яисә фәнни оешма һәм (яисә) гамәлгә куючы тарафыннан тапшырылмаган яисә тапшырылган документлар әлеге күрсәтмәне үтәүне расламаган очракта, мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек органы мәгариф учреждениесен яисә фәнни оешманы дәүләт аккредитациясеннән тулысынча яисә аерым белем бирү программаларына, шушы мәгариф учреждениесендә яисә фәнни оешмада һәм (яисә) аларның филиалларында гамәлгә ашырыла торган әзерлек һәм белгечлек юнәлешләренең эреләндерелгән төркемнәренә карата мәхрүм итә.";

в) түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

"2.1. Мәгариф өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, тикшерүләр уздыруга Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә экспертлар һәм эксперт оешмалары җәлеп ителә.

Мәгариф өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга, юридик затларны тикшерүләрне оештыруга һәм уздыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.";

19) III бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 35.2 һәм 35.3 статьялар өстәргә:

"35.2 статья. **Мәгариф эшчәнлеген лицензияләү**

Мәгариф эшчәнлеген лицензияләү Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

35.3 статья. **Мәгариф учреждениеләрен, фәнни оешмаларны дәүләт аккредитацияләве**

Мәгариф учреждениеләрен, фәнни оешмаларны дәүләт аккредитацияләве Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.";

20) 45 статьяда:

а) 16 пунктка "учреждениеләрендә" сүзеннән соң "укытуның көндезге рәвеше буенча" сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 17 һәм 18 пунктлар өстәргә:

"17. Дәүләт аккредитациясе булган гомуми белем учреждениесенең яисә башлангыч һөнәри белем мәгариф учреждениесенең эшчәнлеген туктаткан очракта, шулай ук тиешле лицензияне юкка чыгарган, мәгариф учреждениесен дәүләт аккредитациясеннән мәхрүм иткән, дәүләт аккредитациясе турындагы таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамланган очракта, мондый мәгариф учреждениесенең гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) укучыларны, тәрбияләнүчеләрне ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән тиешле типтагы башка мәгариф учреждениеләренә күчерүне тәэмин итә.

Урта һөнәри яисә югары һөнәри белем мәгариф учреждениесенең эшчәнлеген туктаткан очракта, шулай ук тиешле лицензияне юкка чыгарган, мәгариф учреждениесен дәүләт аккредитациясеннән мәхрүм иткән, дәүләт аккредитациясе турындагы таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамланган очракта, мондый мәгариф учреждениесенең гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә, уку хакын түләү каралган килеш, физик һәм (яисә) юридик затлар белән шартнамәләр буенча чыгымнарны каплауны тәэмин итә. Урта һөнәри яисә югары һөнәри белемнең граждан дәүләт яисә муниципаль мәгариф учреждениесенең гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) шулай ук укучыларны тиешле типтагы башка мәгариф учреждениеләренә күчерүне тәэмин итә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән күчерүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

18. Укучы төп гомуми белем яисә урта (тулы) гомуми белем алган чорда аны сәнгать өлкәсендә урта һөнәри белемнең интеграцияләнгән белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениесеннән чыгару турындагы карар кабул ителгән очракта, әлеге мәгариф учреждениесе укучыны төп гомуми белемнең, урта (тулы) гомуми белемнең төп белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы башка мәгариф учреждениесенә күчерүне мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә тиеш.";

21) 47.1 статьяның 3 пунктындагы икенче абзацында "Россия Федерациясе субъектының тиешле мәгариф оешмалары урнашкан территориядәге" сүзләрен "Татарстан Республикасы территориясендәге" сүзләренә алмаштырырга;

22) 52 статьяның 4 пунктындагы дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"– эшләгән еллары өчен Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә пенсия яше җиткәнче пенсия алуга, торак мәйданын беренче чиратта алуга. Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) яшәүче һәм эшләүче педагогика хезмәткәрләре торак урыннары, җылылык һәм яктылык өчен түләү чыгымнарын компенсацияләүгә хокуклы. Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф учреждениеләренең һәм муниципаль мәгариф учреждениеләрнең педагогика хезмәткәрләренә социаль ярдәмнең әлеге гамәлләрен башкаруга бәйле чыгымнарны каплау күләме, шартлары һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә;".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 18 ноябре
№ 92-ТРЗ